# Таң

Мәсгудә Шәмсетдинова музыкасы
Разил Вәлиев сүзләре




йо - кы - сын - нан у - ян - ды,
Ул күз - лә - рен а - чу бе - лән
ал - ла - нып о - фык ян - ды.




Зәңгәр яулык япкан иртә
Йокысыннан уянды,
Ул күзләрен ачу белән
Алланып офык янды.

Һәм ул күрде шаян җилнең
Агачны уятканын,
Тулган айның тау артында
Югалганын, батканын.

Аннан күрде юынганын
Чык белән үләннәрнең,
Һәм ишетте чәчәкләрнең
Чылтырап көлгәннәрен.

Тыңлады ул тыпылдавын
Иң соңгы тамчыларның,
Кояш алтын нуры белән
Тәрәзә шакыганын.